СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.12.2025 Баулы шәһәре №22

Баулы муниципаль район Советының «Баулы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 150 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 996 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль район Советының «Баулы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 150 номерлы карарына (Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 177 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 275 номерлы, 2022 елның 22 февралендәге 104 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 152 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 258 номерлы, 2024 елның 8 ноябрендәге 274 номерлы, 2025 елның 15 маендагы 311 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Баулы муниципаль районы муниципаль берәмлегендәге бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретареның вазыйфаи оклады күләменә туры китереп исәпләнә, ул 16 928 сум тәшкил итә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чykканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә.

Баулы муниципаль районы башлыгы,
Район Советы рәисе И.И. Гозәеров